КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 август г.Казань № 759

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республи-касының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 4 июнь, 407 нче; 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче; 2016 ел, 6 август, 533 нче; 2016 ел, 12 декабрь, 918 нче; 2017 ел, 21 март, 168 нче; 2017 ел, 12 сентябрь, 649 нчы; 2018 ел, 1 декабрь, 1070 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1093 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 814 нче; 2019 ел, 22 ноябрь, 1065 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1263 нче; 2020 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы, 2020 ел, 06 март, 180 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәре-шләрне кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.1.11 пунктча өстәргә:

«2.1.11. Татарстан Республикасында милли проектлар составында төбәк проектларын гамәлгә ашыруны координацияләү»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Министрлык функцияләре

3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*):

озак вакытка социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.01*);

планлаштырылган елга социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.02*);

инвестицион эшчәнлекне өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

интеллектуаль милек өлкәсен үстерү белән идарә итү (01.11.01*);

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

кара һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү (01.19*);

икътисадны мобилизацион әзерләү белән идарә итү (02.04*);

социаль өлкә белән идарә итү (04*);

3.2. Министрлык хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы белән мәгълүматлаштыру белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда (01.15*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү (01.12*);

мәгариф белән идарә итү (04.05*);

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән массакүләм мәгълүмат чаралары аша җәмгыятьтә толерант мөнәсәбәтләрне саклау өлкәсендә этномәдәни проектларны (мәдәният өлкәсендәге проектларны) тормышка ашыруда катнашучы иҗтимагый берләшмәләргә, милли иҗтимагый берләшмәләргә дәүләт ярдәме күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашырганда (01.24*);

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән сәламәтлек саклау белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.02*);

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

---

* Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторы буенча кодны билгеләү.

Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендә җәмәгать берләшмәләре эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен тәэмин итү (01.23*);

авыл хуҗалыгы белән идарә итү (03.02*);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә функциясен тормышка ашырганда (01.06*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

территориаль планлаштыру (01.05.01*);

билгеләнгән тәртиптә гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән идарә итү (04.01*);

архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый берләшмәләрнең эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.25*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә функцияләрен тормышка ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән транспорт комплексы белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү функциясен тормышка ашырганда (03.03*);

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.04*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне тормышка ашырганда:

хезмәт белән идарә итү (01.13*);

халыкны эш белән тәэмин итү, социаль хезмәт күрсәтү һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыручы инвалидларның, ветераннарның һәм пенсионерларның иҗтимагый берләшмәләре, шулай ук коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.27*);

социаль яклау белән идарә итү (04.06*);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә эшчәнлек белән идарә итү (01.03*);

энергияне һәм ресурсларны саклау белән идарә итү (01.14*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

эчке товар базарының аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешен җайга салу (03.05*);

эчке товар базарының аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр (этил спирты, алко-

гольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнештән тыш) белән тәэмин ителешен билгеләнгән тәртиптә җайга салу (03.05.02*);

социаль-икътисадый хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары белән хезмәттәшлеген тәэмин итү (03.07*);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә (04.07*);

яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.26*);

Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты белән туризм өлкәсендә идарә функцияләрен тормышка ашырганда (04.09*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләт-шәхси партнерлык һәм шәхси инвестицияләр өлкәсендә инвестицион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда, инвестицион проектларны тормышка ашыруны комплекслы тәэмин итү (01.10*);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.10*);

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау буенча комитеты белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы территориясендә мәдәни мирас объектларын саклау (саклау, файдалану һәм популярлаштыру) өлкәсендә иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.28*);

Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектларын саклау, куллану һәм популярлаштыру (04.03.03*).»;

4.1 пунктта:

4.1.82.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.82.6. Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зона белән идарә итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра (проект документларына һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза үткәрүне тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш), шул исәптән:

махсус икътисадый зоналар резидентлары реестрларын алып бару;

махсус икътисадый зоналар резидентлары таләпләре буенча яисә кызыксынган затлар соравы буенча махсус икътисадый зоналар резидентлары реестрларыннан өземтәләр бирү;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Махсус икътисадый зона резиденты тарафыннан махсус икътисадый зонада сәнәгать-җитештерү, техник-гамәлгә кертү, туристик-рекреация эшчәнлеген яки эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы Килешүнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау

турында» 2016 елның 23 августындагы 530 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә махсус икътисадый зоналар резидентлары тарафыннан сәнәгать-җитештерү, техник-гамәлгә кертү, туристлык-рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы килешүләрнең махсус икътисадый зона резидентлары тарафыннан үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

«Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә техник-гамәлгә кертү яисә сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешүләр төзү;

махсус икътисадый зоналар чикләрендә территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү һәм бу зоналарда инженерлык, транспорт, социаль, инновацион һәм башка инфраструктура булдыру буенча дәүләт заказчысы функцияләрен үтәү, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәгән булса.»;

4.1.82.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.82.7. Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы һәм «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы указлары кысаларында Татарстан Республикасында төбәк проектларын гамәлгә ашыру буенча проект эшчәнлеген гомуми координацияләүне тәэмин итә, шулай ук аларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына консультацион-методик ярдәм күрсәтә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.82.9 һәм 4.1.82.10 пунктчалар өстәргә:

«4.1.82.9. Татарстан Республикасында төбәк проектларында катнашучылар тарафыннан проект эшчәнлегенең мәгълүмати системасында тәкъдим ителә торган күрсәткечләргә, нәтиҗәләргә, контроль нокталарга һәм региональ проектларны тормышка ашыру куркынычларына ирешү турындагы мәгълүматның дөреслеген, актуальлеген, тулылыгын һәм корректлылыгын тикшереп торуны гамәлгә ашыра һәм әлеге мәгълүматны эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр формалаштыра.

4.1.82.10. Төбәк проект офисы эшчәнлеген аналитик яктан тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин